**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре | № 122-15 | «25» февраль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавына, аның социаль-икътисадый үсеше стратегиясенең һәм Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемаларының һәм Азнакай муниципаль районының расланган стратегиясенең федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмавына бәйле рәвештә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең генераль планын эшләүдә ихтыяҗ булмавын таныrга.
2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай район Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин